*Балачак көзгесе кулда,*

*“Сабантуй”га 100 тулды...*

*Балаларда туган телгә мәхәббәт, табигатькә сакчыл караш, әти-әниләргә, якыннарыбызга хөрмәт хисе, белемгә омтылыш, зирәклек, тапкырлык тәрбияләүче “Сабантуй” журналы 2024 елның 10 октябрендә үзенең 100 еллык бәйрәмен билгеләп үтте. Шул уңайдан 14 октябрь көнне “79 нчы номерлы экология-технология” лицеенда журналны әзерләүче журналистларыбыз - "Сабантуй"ның баш мөхәррир урынбасары Руфия Мөхетдинова һәм язучы Айсылу Имамиева кунакта булдылар. Кунаклар лицей укучыларын журнал белән якыннанрак таныштырды: гәзиттә кайчандыр танылу тапкан бүгенге көннең күренекле язучы-шагыйрьләре хакында мәгълүмат җиткерделәр, кызыклы рубрикалар хакында сөйләделәр, укучыларга журнал битләрендә популяр булу серләрен аңлаттылар. Лицей укучылары да журналистлар белән очрашуга ныклап әзерләнгән иде: 4Б сыйныф укучылары Егоров Әмир һәм Айзилә Ганиева кичәне туган телебезгә багышланган шигырь белән ачып җибәрде. Очрашуда 1963 елда балалар шагыйре Шәүкәт абый Галиевның халык тарафыннан яратып кабул ителгән герое – Шәвәли дә кунакта булды. Бактың исә, балалар шагыйре Шәвәли хакындагы шигырьләрне үз укучыларына 1963 елда нәкъ менә әлеге газета аша тәкъдим иткән булган икән. Кичә җырга-моңга үрелеп барды, укучылар журналистларга кызыксындырган сорауларын да бирделәр.*

*“Сабантуй” хезмәткәрләре экология юнәлешендә эшләүче лицей укучыларына журналда экология темасын яктыртучы сәхифә эшләү тәкъдиме белән чыктылар.*

*Әлеге истәлекле мизгелләр лицей укучылары күңелендә матур бер хатирә булып озак сакланыр дип ышанабыз.*


100
Сабантуй
РТ
Яшь
ЛЕНИНЧЫ
100
ел


Сабантуй РТ
Яшь
ЛЕНИНЧЫ
100 ел


Сабантуй
100
Яшь
ЛЕНИНЧЫ
100
Яшь ленинчы


Гаяз Исхаки (1878–1954)
Татарский писатель, журналист.
В советское время до 1930-х годов
произведения Исхаки включались в школьные
программы, по ним ставились спектакли.
В 1991 г. была учреждена Премия Союза
писателей РТ им. Г. Исхаки.
Шигабутдин Марджани
Кырны туттырып алтын бодай үссен,


100 ел
Сабантуй


Сабантуй
100
РТ
Яшь
ЛЕНИНЧЫ

